# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Баганино урман хуҗалыгы пос. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

18 декабрь 2021 е. № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге составына керүче Баганино урман хуҗалыгы пос. торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьларын сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Майна авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

2. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Майна авыл җирлеге башлыгы** **Р.Н.Гафиятуллин**